| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ГЛАВА БУРМЕТЬЕВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>НУРЛАТСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КИЕКЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>БАШЛЫГЫ |
|---|---|---|

ПОСТАНОВЛЕНИЕ Киекле ав. КАРАР

«2» ноябрь 2020 ел № 3

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлеге Үрнәк авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Нурлат муниципаль районының Киекле авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2020 елның 20 ноябрендә 9 сәгать 00 минутка Үрнәк авылы, Нагорная урамы, 58А адресы буенча урнашкан мәчет бинасы янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлегенең Үрнәк авылында Нагорная урамында яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын уздыруны билгеләргә.
2. 2020 елның 20 ноябрендә 11 сәгать 00 минутка Үрнәк авылы, Нагорная урамы, 19 нчы йорт адресы буенча урнашкан йорт янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлеге Үрнәк авылы Нагорная урамында яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын уздыруны билгеләргә.
3. Үрнәк авылында яшәүчеләрнең исемлеген гражданнар җыенын үткәрү өчен сайлау тәртибен территориаль билге буенча эшләргә.
4. Үрнәк авылы Нагорная урамында яшәүче гражданнар өчен гражданнар җыенының этапларын үткәрү һәм оештыру Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлеге башлыгы һәм башкарма комитеты тарафыннан тәэмин ителә.
5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләләрне расларга:

«Киекле авыл җирлегенең Үрнәк авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм яшәүче, 1 гр инвалидлардан, балачактан инвалид булганнарның, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан кала, балигъ булган һәр кешедән 2021 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту һәм ремонтлау, шул

исәптән Үрнәк авылы территориясендәге юлларны сезонлы карап тоту, юл кырыйларына таш, ватылган кирпеч, грунт, вак таш, ком түшәү (сатып алу, ташу, җәю).
Үрнәк авылында урамнарны яктыртуны оештыру өчен эшләр һәм хезмәтләр, товарлар сатып алу.
Үрнәк авылы зиратын төзекләндерү һәм сезонлы карап тоту (коймаларны ремонтлау, агачларны кисү, үлән чабу).
« РИЗА» «КАРШЫ».

6. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (игълан итәргә), Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авылының мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча урнаштырырга.

11. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Киекле авыл җирлеге башлыгы
вазыйфаларын башкаручы Р.Ә.Заһертдинова